ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«03» апрель 2024 ел Биклән авылы № 3

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге составына керүче Кзыл-Юл авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Кзыл-Юл авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Кзыл-Юл авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Биклән авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Советының

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге составына керүче Кзыл-Юл авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Кзыл-Юл авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрелена 15.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге составына керүче Кзыл-Юл авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 16 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 16 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Бакчасарай авылында гражданнар җыены карарына:
«-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Биклән авыл җирлеге, Кзыл-Юл авылы, Үзәк урамы, 11нче йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Биклән авыл җирлеге Башлыгы М.Ш. Сәхбеев